4) капиталь төзелеш объектын кабул итеп алу акты (төзелеш подряды килешүе нигезендә төзелеш, төзекләндерү гамәлгә ашырган очракта);

5) төзелгән, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектының параметрлары проект документациясенә тәңгәл килүен дәлилләүче, шул исәптән энергия нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергия ресурсларын исәпләү җиһазлары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүен дәлилләүче һәм төзелешне гамәлгә ашырган зат тарафыннан (төзелеш подряды килешүе нигезендә төзелеш, төзекләндерүне гамәлгә ашырган очракта төзелешне гамәлгә ашыручы зат, һәм төзүче яки техник заказчы, шулай ук килешү нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашырган очракта төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан) имзалаган акт;

6) төзелгән, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектының техник шартларга тәңгәл килүен дәлилләүче һәм энергия-техник тәэмин ителеш челтәрләрен эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларның вәкилләре тарафыннан имзаланган документлар (алар булган очракта) (2011 елның 18 июлендәге 243-ФЗ номерлы Федераль закон белән 2011 елның 22 июлендә гамәлгә кертелгән редакциясендәге пункт, - моннан алдагы редакцияне карарга);

7) линия объектын төзү, төзекләндерү очракларыннан тыш, төзелгән, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объекты урнашуын, җир кишәрлеге чикләрендә инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре урнашуын һәм җир кишәрлегенең планлаштырылган оештырылышын сурәтләгән, һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан (төзелеш, төзекләндерү төзелеш подряды килешүе нигезендә гамәлгә ашырылган очракта, төзелешне гамәлгә ашыручы зат, һәм төзүче яки техник заказчы тарафыннан) имзалаганган схема;

8) төзелгән, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объекты проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергия нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергия ресурсларын исәпләү җиһазлары белән тәэмин ителеш таләпләренә тәңгәл килүе турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсе (әгәр дәүләт төзелеш күзәтчелеген Кодексның 54 статьясы 1 өлеше нигезендә гамәлгә ашыру каралган булса), Кодексның 54 статьясы 7 өлешендә каралган очракларда бирелүче, башкарма хакимият федераль органы федераль дәүләт экологик күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтләнең (алга таба – федераль дәүләт экологик күзәтчелек органы) бәяләмәсе;

9) Россия Федерациясенең куркыныч объект хуҗасының куркыныч объектта авария нәтиҗәсендә зыян китергән өчен гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү турындагы законнары нигезендә, куркыныч объект хуҗасының куркыныч объектта авария нәтиҗәсендә зыян китергән өчен гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү килешүен төзүне дәлилләүче документ;

10) «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) объектлары турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законы белән билгеләнгән, тиешле мәдәни мирас объектларын саклау органы белән расланган, мәдәни мирас объектларын саклау буенча, әлеге объектны төзекләндерү, консервацияләү, ремонтлау үткәргәндә һәм аны заманча файдалануга яраклаштырганда башкарылган эшләрне кабул итеп алу акты;

11) «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнгән капиталь төзелеш объекты техник планы.

Документлар бер экземплярда тәкъдим ителә.

